ЯШӘСЕН ВАТАНЫБЫЗНЫҢ НАМУСЫ, АЗАТЛЫГЫ ҺӘМ БӘЙСЕЗЛЕГЕ ӨЧЕН НЕМЕЦ-ФАШИСТ БАСЫП АЛУЧЫЛАРГА КАРШЫ ГЕРОЙЛАРЧА КӨРӘШҮЧЕ КЫЗЫЛ АРМИЯ!

СИШӘМБЕ
23 ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 44 (6766)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Верховный Баш Командующийның ПРИКАЗЫ

23 ФЕВРАЛЬ, 1943 ел. **№ 95** *МОСКВА ШӘҺӘРЕ*

Иптәшләр! Кызылармеецлар һәм кызыл флотчылар, командирлар һәм политработниклар, партизаннар һәм партизанкалар! Бүген без Кызыл Армия яши башлауның 25 еллыгын бәйрәм итәбез.

Кызыл Армия төзелгәннән бирле чирек гасыр үтте. Ул, безнең илебезне кол итәргә омтылган чит ил басып алучыларына каршы көрәшү өчен төзелде. 1918 нче елның 23 нче феврале, Кызыл Армия отрядларының Псков һәм Нарва янында немец басып алучылар гаскәрләрен баштанаяк җимергән көне—Кызыл Армиянең туган көне дип игълан ителде.

1918—1921 нче елларда Кызыл Армия чит ил басып алучыларына каршы каты көрәштә безнең Совет Ватаныбың намусын, азатлыгын һәм бәйсезлеген саклап калды, безнең илебез халыкларының үз тормышларын бөек Ленин өйрәткәнчә төзү хокукын саклап калды.

Кызыл Армия, егерме ел буена, совет халкының тыныч иҗат хезмәтен саклап килде. Безнең илебезнең халыклары чит ил басып алучыларының безнең җиребезгә кул сузуларын беркайчан да онытмадылар һәм Кызыл Армиянең куәтен ныгыту турында туктаусыз кайгырттылар, аны беренче класслы сугыш техникасы белән коралландырдылар һәм совет сугышчылары кадрларын мәхәббәт белән үстерделәр.

Кызыл Армия—барлык илләрдәге халыклар арасында тынычлыкны һәм дуслыкны саклау армиясе. Ул читләр җирен басып алу өчен түгел, бәлки Советлар иле чикләрен саклау өчен төзелде. Кызыл Армия барлык халыкларның хокукларына һәм бәйсезлегенә һәр вакытта да ихтирам белән карады.

Ләкин 1941 нче елның июнендә Гитлер Германиясе, һөҗүм итешмәү турындагы договорны тупас һәм кабахәт рәвештә бозып, хыянәтчел төстә безнең илебезгә һөҗүм итте. Һәм Кызыл Армия үзенең ватанын немец басып алучылардан саклап калу һәм аларны илебез чикләреннән куу өчен походка чыгарга мәҗбүр булды. Шул вакыттан алып Кызыл Армия Гитлер гаскәрләренә каршы үлем көрәше армиясе булып, ватаныбызның оккупацияләнгән районнарында безнең туганнарыбызга карата немец-фашист кабахәтләр тарафыннан эшләнә торган көчләүләр һәм кимсетүләр өчен үч алучылар армиясе булып әверелде.

Яшәвенең 25 еллыгын Кызыл Армия Гитлер Германиясенә һәм аның ялчылары булган итальяннарга, венгерларга, румыннарга, финнарга каршы ватан сугышының хәлиткеч моментында каршылый.

Немец-фашист яуларының басып керүенә каршы Кызыл Армиянең тарихта тиңдәше булмаган героик көрәш алып бара башлавына 20 ай тулып үтте. Европада икенче фронт булмаганга күрә Кызыл Армия бер ялгызы сугышның бөтен авырлыгын үз җилкәсендә күтәреп бара. Шулай булса да Кызыл Армия немец-фашист яуларының басымына каршы торып кына калмады, бәлки сугыш барышында фашистлар армияләре өчен дәһшәт булып та әверелде.

1942 нче елның җәендә һәм көзендә булган авыр сугышларда Кызыл Армия фашист ерткычның юлын кисте. Севастопольның һәм Одессаның героик оборонасы истәлеген, Москва янында һәм Кавказ таулары алдында, Ржев районында һәм Ленинград янында булган каты сугышлар истәлеген, Сталинград стеналары янында сугышлар тарихындагы иң зур сугыш истәлеген безнең халкыбыз мәңге саклар. Бу бөек сугышларда безнең батыр сугышчыларыбыз, командирларыбыз һәм политработникларыбыз Кызыл Армиянең сугышчан байракларын мәңгелек дан белән бизәделәр һәм немец фашистлары армияләрен җиңү өчен ныклы нигез салдылар.

Моннан өч ай элек Кызыл Армия гаскәрләре Сталинградка килү юлларында һөҗүм башладылар. Шул вакыттан бирле сугыш хәрәкәтләре инициативасы безнең кулда, һәм Кызыл Армиянең һөҗүм операцияләренең темплары һәм удар көче йомшамый. Хәзер Кызыл Армия кышкы авыр шартларда 1.500 километр озынлыктагы фронт буйлап һөҗүм алып бара һәм һәркайда да диярлек уңышларга ирешә. Төньякта, Ленинград янында, Үзәк фронтта, Харьковка килү юлларында, Донбасста, Ростов янында, Азов һәм Кара диңгез ярларында Кызыл Армия Гитлер гаскәрләренә бер-бер артлы ударлар ясый. Өч ай эчендә Кызыл Армия Воронеж һәм Сталинград өлкәләрен, Чечен-Ингуш, Төньяк Осетия, Кабардино-Балкария һәм Калмык Автономияле республикаларын, Ставрополь һәм Краснодар крайларын, Черкес, Карачай һәм Адыгей автономияле өлкәләрен, Ростов, Харьков һәм Курск өлкәләренең бөтен территориясен диярлек дошманнан азат итте.

Дошманны Советлар иленнән массовый төстә куу башланды.

Бу өч ай эчендә нәрсәләр үзгәрде? Немецларның мондый җитди уңышсызлыклары нәрсәдән килеп чыкты? Бу уңышсызлыкларның сәбәпләре кайда?

Совет—Германия фронтында көчләрнең чагыштырмасы үзгәрде. Эш шунда ки, фашистлар Германиясе торган саен хәлсезләнә һәм көчсезләнә бара, ә Советлар Союзы үзенең резервларын торган саен җәелдерә

(Ахыры 2 нче биттә)

БЕЗНЕҢ УРАМГА ДА БӘЙРӘМ КИЛДЕ

Чирек гасыр моннан элгәре
Армиябез туган көннәрне
Хәтерләтеп,
Шаулый ил өстендә
Яз җилләре—җиңү җилләре.

Яңгыратып җиңү маршын
Уйный бүген көмеш боргылар:
— Бәйрәм килде безнең урамга!
Куансаң да бүген урыны бар.

Байракларда
Февраль кояшының
Чагылдырып янтарь нурларын,
Котлый халык —
Алга, Көнбатышка
Сәфәр тоткан батыр улларын.

— Ир йөрәкле асыл егетләр!
Мәңгелек дан Сезгә һәм рәхмәт!
Авыр походларда юлдаш булып
Бергә барсын безнең мәхәббәт.

Гади солдат кебек шинель киеп,
Сезнең белән бергә—иң алдан,
Җиңүгә аз салып,
Юл күрсәтеп
Баручыга безнең сәлам! Дан!

Фронт сызыгын алга, көнбатышка
Күчерә барган кызыл байракта
Аның исеме балкый көрәш булып,
Якты нурын сибеп һәрьякка.

Аның исеме белән атакага
Бара илнең батыр ирләре.
Аның исемен җырлап исә бүген
Яз җилләре—
Җиңү җилләре!

КАВИ НӘҖМИ.

ЯШӘСЕН БӨТЕНСОЮЗ КОММУНИСТЛАР (БОЛЬШЕВИКЛАР) ПАРТИЯСЕ, НЕМЕЦ- ФАШИСТ БАСЫП АЛУЧЫЛАРНЫ ҖИҢҮ КӨРӘШЕН ОЕШТЫРУЧЫ ЛЕНИН—СТАЛИН ПАРТИЯСЕ!

(ВКП (б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ЛОЗУНГЛАРЫННАН

Верховный Баш Командующийның ПРИКАЗЫ

(Ахыры, башы 1 нче биттә).

һәм көчлерәк була бара. Вакыт фашистлар Германиясенә каршы эшли.

Европаның хәрби промышленностен үзе өчен эшләргә мәҗбүр иткән Гитлер Германиясе соңгы вакытларга кадәр техника ягыннан һәм бәрыннан да элек танклар һәм самолетлар ягыннан Советлар Союзына карaганда өстен булып килде. Аның өстенлеге шушы иде. Ләкин сугышның егерме ае эчендә хәл үзгәрде. СССР хәрби промышленносте эшчеләренең, эшче хатын-кызларының, инженерларының һәм техникларының үз-үзләрен аямыйча эшләүләре аркасында, сугыш вакытында танклар, самолетлар, орудиеләр эшләп чыгару артты. Шул ук вакыт эчендә Совет—Германия фронтында дошман гаять күп сугыш техникасын, бигрәк тә танкларын, самолетларын һәм орудиеләрен югалтты. 1942—1943 нче елның кышында Кызыл Армия һөҗүменең өч ае эчендә генә дә немецлар 7.000 нән артык танк, 4.000 самолет, 17.000 орудие һәм башка төрле күп коралларын югалттылар.

Билгеле, немецлар бу югалтуларны кайтарырга тырышачаклар, ләкин моны эшләү бик җиңел булмас, чөнки дошманның бу югалган гаять күп техникасын яңадан тулыландыра алуы өчен күп вакыт кирәк булачак. Ә вакыт көтми.

Гитлер Германиясе СССР га каршы сугышны мобилизацияләнгән һәм сугышка әзер булган гаскәрләренең Кызыл Армиягә чагыштырганда сан ягыннан өстен булуы хәлендә башлады. Аның өстенлеге шушы иде. Ләкин 20 ай эчендә бу яктан да хәл үзгәрде. Оборона һәм һөҗүм сугышларында Кызыл Армия сугыш башланганнан бирле 9 миллионга якын немец-фашист солдатларны һәм офицерларны сафтан чыгарды, шулардан кимендә 4 миллионы сугыш кырында үтерелде. Гитлер тарафыннан Совет—Германия фронтына җибәрелгән румын, итальян һәм венгер армияләре бөтенләй тар-мар ителделәр. Соңгы өч ай эчендә генә дә Кызыл Армия дошманның 112 дивизиясен җимерде, шул вакытта 700.000 нән артык кеше үтерелде һәм 300.000 нән артык кеше пленга алынды.

Билгеле, бу гаять зур югалтуны кайтару өчен немецлар командованиесе бөтен чараларны күрер. Ләкин, беренчедән, немец армияләренең йомшак урыны—кешеләр резервлары җитешмәүдә, шунлыктан бу югалтуларның нинди чыганаклардан алып капланачагы билгесез. Икенчедән, әгәр дә хәтта немецлар кирәк кадәр сандагы кешеләрне барлык дөрес булган һәм дөрес булмаган юллар белән кырып-себереп җыярлар дип уйлаганда да әле аларны җыю һәм өйрәтү өчен күп вакыт кирәк булачак. Ә вакыт көтми.

Гитлер армиясе Советлар Союзына каршы сугышка Европада сугышның иң яңа средстволарын кулланып, зур сугыш операцияләре алып бару буенча ике еллык диярлек тәҗрибәсе булган хәлдә керде. Табигый ки, сугышның беренче чорында Кызыл Армиянең әле андый сугыш тәҗрибәсе юк иде һәм булырга да мөмкин түгел иде. Немец фашистлары армиясенең өстенлеге шушы булды. Ләкин егерме ай эчендә хәл бу яктан да үзгәрде. Сугыш барышында Кызыл Армия кадровый армия булып әверелде. Ул, дошманны, хәзерге заман сугыш фәне таләп иткәнчә, аның йомшак һәм көчле якларын исәпкә алып, ышанычлы рәвештә кыйнарга өйрәнде. Кызыл Армиянең йөз меңнәрчә һәм миллионнарча сугышчылары үз коралларының мастерлары булып—винтовка, кылыч, пулемет, артиллерия, миномет эше, танк эше, саперлык эше, авиация мастерлары булып әвеределәр. Кызыл Армиянең ун меңнәрчә командирлары гаскәрләргә җитәкчелек итү мастерлары булып әверелделәр. Алар шәхси батырлыкны һәм гайрәтлелекне сугыш кырында гаскәрләргә җитәкчелек итә белү белән бергә бәйләргә өйрәнделәр, ахмак һәм зарарлы булган линия тактикасыннан ваз кичеп, маневр ясау тактикасы җирлегенә нык итеп аяк бастылар.

Кызыл Армия командованиесенең совет җирен дошманнан азат итү белән генә калмыйча, дошман армияләрен чолгап алу һәм бетерү буенча сугыш сәнгате үрнәге булып хезмәт итәрлек җитди операцияләрне тормышка ашырып, дошманны безнең җиребездән исән килеш чыгармый калуы фактын очраклы хәл дип санап булмый. Бу, һичшиксез, безнең командирларыбызның җитлеккәнлеге билгесе.

Һичшиксез, Сталинград янында немецларның 330 мең кешедән торган, сайлап алынган гаять зур армиясен чолгап алу һәм бетерү шикелле шундый күренекле фактка бары тик Кызыл Армия командованиесенең дөрес стратегиясе һәм безнең башкаручы командирларыбызның җитез тактикасы гына китерә алды.

Бу яктан алганда немецларның хәле бик үк шәптән түгел. Аларның стратегиясе кимчелекле, чөнки ул, кагыйдә буларак, каршы якның көчләренә һәм мөмкинлекләренә бәя биреп җиткерми һәм үз көчләренә тиешеннән артык бәя бирә. Аларның тактикасы—шаблон тактика, чөнки ул фронттагы вакыйгаларны уставның теге яки бу параграфына туры китерергә тырыша. Обстановка устав таләпләрен тормышка ашырырга мөмкинлек биргән вакытта немецлар үзләренең хәрәкәтләрендә пөхтә һәм төгәл эш итүче кешеләр. Аларның көче шунда. Обстановка катлаулангач һәм, уставның теге яки бу параграфына «туры килмичә», үзлегеңнән уставта күрсәтелмәгән карарга килүне таләп итә башлагач немецлар көчсез булып әвереләләр. Аларның төп йомшаклыгы шунда.

Соңгы өч ай эчендә немец гаскәрләренең җиңелүен һәм Кызыл Армиянең уңышларын китереп чыгарган сәбәпләр шулар.

Ләкин бу әле Гитлер армиясе инде бетерелгән дигән сүз түгел һәм Кызыл Армиягә аны илебезнең көнбатыш чикләренә куып барырга гына кала дигән сүз түгел. Болай уйлау—үзеңне акылсыз һәм зарарлы юатуга бирелү дигән сүз. Болай уйлау—үз көчләреңә тиешеннән артык бәя бирү, дошман көчләренә бәя биреп җиткермәү һәм авантюризмга ташлану дигән сүз. Дошманга зыян китерелде, ләкин ул әле җиңелмәде. Немец фашистлары армиясе Кызыл Армиядән алынган ударлар нәтиҗәсендә кризис кичерә, ләкин бу әле—ул яңадан айный алмас дигән сүз түгел. Немец басып алучыларга каршы көрәш әле бетмәгән,—ул әле җәелеп һәм кабынып кына бара. Немецлар безнең җиребезнең бер генә километрын булса да сугышмыйча ташлап китәрләр дип уйлау ахмаклык булыр иде.

Кызыл Армия алдында мәкерле, рәхимсез һәм хәзергә әле көчле булган дошманга каршы каты көрәш тора. Бу көрәш вакыт сорый, корбаннар сорый, көчләребезне җигүне һәм барлык мөмкинлекләребезне туплауны сорый. Без Советлар Украинасын немецлар изүеннән азат итә башладык, ләкин миллионнарча украинлылар әле немец кол биләүчеләр изүе астында торалар. Белоруссиядә, Литвада, Латвиядә, Эстониядә, Молдавиядә, Кырымда, Карелиядә әле хәзергә немец оккупантлар һәм аларның ялчылары хуҗалык итә. Дошман армияләренә куәтле ударлар ясалды, ләкин әле дошман җиңелмәгән. Немец басып алучылар ярсынып каршылык күрсәтәләр, контратакаларга күчәләр, оборона чикләрендә тотынып калырга маташалар һәм аларның яңа авантюраларга барулары мөмкин. Менә шуңа күрә дә безнең сафларыбызда тыныч күңеллелеккә, гамьсезлеккә, масаюга урын булмаска тиеш.

Кызыл Армиянең җиңүләренә бөтен совет халкы шатлана.

Кызыл Армиянең сугышчылары, командирлары һәм политработниклары остазыбыз Ленинның: «Беренче эш—җиңү белән мавыкмаска һәм масаймаска, икенче эш—җиңүне үзеңнеке итеп беркетергә, өченче эш—дошманны кыйнап бетерергә» дигән васыятьләрен исләрендә нык тотарга тиешләр.

Ватаныбызны явыз дошманнан азат итү өчен, немец-фашист басып алучыларны тәмам җиңү өчен,—

Приказ бирәм:

1. Бөтен Кызыл Армиядә һәм Хәрби Диңгез Флотында сугыш эшенә өйрәнүне туктаусыз яхшыртырга, дисциплинаны, тәртипне һәм оешканлыкны ныгытырга.

2. Дошман гаскәрләренә ударларны көчәйтергә, дошманны туктаусыз һәм ныклык белән куып барырга, аңа оборона чикләрендә ныгырга ирек бирмәскә, аңа көндез дә, төнлә дә ял итәргә ирек бирмәскә, дошманның коммуникацияләрен кисәргә, дошман гаскәрләрен чолгап алырга һәм, әгәр дә корал ташлаудан баш тартсалар, аларны юк итәргә.

3. Дошман тылында партизаннар көрәше ялкынын киңрәк кабызырга, дошманның коммуникацияләрен җимерергә, тимер юл күперләрен шартлатырга, дошман гаскәрләрен ташуны, кораллар һәм сугыш припаслары китерүне өзәргә, дошманның хәрби складларын шартлатырга һәм яндырырга, дошман гарнизоннарына һөҗүмнәр ясарга, чигенүче дошманга безнең авылларыбызны һәм шәһәрләребезне яндырырга ирек бирмәскә, һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә бөтен көч белән, барлык средстволар белән булышлык итәргә.

Безнең җиңүебезнең залогы шунда.

Иптәшләр! Кызылармеецлар һәм кызыл флотчылар, командирлар һәм политработниклар, партизаннар һәм партизанкалар!

Совет Хөкүмәте һәм безнең большевиклар партиясе исеменнән сезне сәламлыйм һәм Кызыл Армиянең 25 еллыгы белән котлыйм.

Яшәсен бөек ватаныбыз!

Яшәсен данлыклы Кызыл Армиябез, батыр Хәрби Диңгез Флотыбыз, кыю партизаннарыбыз һәм партизанкаларыбыз!

Яшәсен Кызыл Армиянең җиңүләрен рухландыручы һәм оештыручы большевиклар партиясе!

Немец басып алучыларына үлем!

Верховный Баш Командующий И. СТАЛИН.

Бөтен көчебезне — героик Кызыл Армиябезгә, данлыклы Кызыл Флотыбызга ярдәмгә! Халыкның бөтен көче дошманны тар-мар итүгә! (СТАЛИН).

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

20 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

20 нче февральдә **Украинада**, омтылышлы һөҗүм нәтиҗәсендә Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре **Красноград** шәһәрен һәм тимер юл узелын, **Павлоград** шәһәрен һәм тимер юл узелын, шулай ук район үзәге һәм тимер юл станциясе **Кегичевканы**, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Сахновщинаны**, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Перещепинаны** алдылар.

Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр **Готня** тимер юл узелын, район үзәге һәм тимер юл станциясе **Томаровканы**, район үзәкләре **Борисовканы**, **Ивняны**, **Красная Яруганы** алдылар.

Ростов өлкәсендә безнең гаскәрләр район үзәге **Куйбышевоны** һәм халык яши торган башка күп пунктларны алдылар.

Краснодар районында безнең гаскәрләр район үзәге **Марьянскаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Новомышастовскаяны**, **Ильскаяны**, **Львовскаяны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

19 нчы февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм 4.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Ростов районында тулы булмаган саннар буенча, безнең гаскәрләр 108 танк, 31 орудие, 600 гә якын автомашина, 48 паровоз, 19 мотовоз, 3.984 тимер юл вагоны, шул исәптән сугыш припаслары төялгән 106 вагон, кабель һәм электр җиһазлары төялгән 21 вагон, ашлык төялгән 39 вагон, консервалар төялгән 16 вагон, мотоцикллар, велосипедлар, автомоторлар һәм башка төрле сугыш милекләре һәм снаряжениеләр төялгән күп вагоннар кулга төшерделәр. Аэродромнарда немецларның 15 төзек самолеты һәм 180 ватык самолеты кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Гитлерчылар сугышка бик күп танклар һәм мотопехота кертәләр. Безнең частьлар дошманның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм аңа зур югалтуларга дучар иттеләр. Н-че часть сугышчылары, алга таба барып, 400 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар, дошманның 7 танкысын һәм 23 автомашинасын юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде. Зенит орудиесе наводчигы Степкевич немецларның 2 самолетын атып төшерде.

* * *

Ровенькидан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар. Халык яши торган бер зур пунктта 26 танк, 9 паровоз, 180 автомашина һәм башка төрле күп сугыш милекләре кулга төшерелде.

* * *

Люботиннан көнбатыштарак булган районда безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман көчле ут каршылыгы күрсәтте һәм берничә тапкыр контратакаларга күчте. Бер участокта Н-че часть сугышчылары, артиллериянең куәтле ярдәме белән немецларны көчле итеп ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар. Дошманның 14 орудиесе һәм 2 сугыш припаслары склады юк ителде. Икенче бер участокта безнең моторлаштырылган частьлар сугыша-сугыша алга бардылар, халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Курскидан көнбатыштарак бер участокта немецларның бер батальон пехотасы, 6 танк ярдәме белән, контратакага күчкән иде. Командиры иптәш Бушин булган частьның сугышчылары немецларның 4 танкысын яндырдылар һәм штык сугышында бик күп дошман солдатларын һәм офицерларын кырдылар.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды халык яши торган, немецлар кулындагы зур бер пунктка уңышлы һөҗүм ясаган. Партизаннар 70 гитлерчыны кырганнар, 2 сугыш припаслары складын шартлатканнар, 1.200 центнер ашлыкны кулга төшергәннәр һәм аны җирле халыкка өләшеп биргәннәр. Бер группа партизаннар дошманның гаскәрләр, автомашиналар һәм сугыш припаслары төяп бара торган 3 тимер юл эшелонын һәлак итүне оештырганнар. 3 паровоз һәм 53 вагон юк ителгән. Һәлакәт вакытында күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган.

* * *

Румыннарның 2 нче тау-укчы дивизиясенең 4 нче тау артиллериясе дивизионының 1 нче батареясыннан плен алынган капрал Георге Белтеке болай диде: «Без Баксан авылына барып җиткәч офицерлар безгә күп булса 2-3 атна үтәр һәм сугыш бетәр, диделәр. Капитан Агапий безнең батареяны җыеп, болай диде: «Немец гаскәрләре инде Сталинград шәһәрен алдылар, тик Тбилиси белән Бакуны гына аласы калды һәм румыннар үзләренең туган җирләренә кайтырлар». Полковник Някшу бөтен халыкка ишеттереп, минем дивизионның орудиеләре берничә көннән Бакуга атачаклар, дип мактанды. Ләкин эшкә килгәндә бөтенесе башкача булып чыкты. Руслар безгә төзәлмәслек удар ясадылар. Безнең дивизиябез кешеләр составының 75 процентын югалтты. Шулай ук, минем подразделениеләр Бакуга беренче булып керәчәкләр, дип мактанган полковник Някшу да үтерелде. Безнең офицерлар рухсызландылар һәм каушадылар. Чигенгән чакта румыннар белән немецлар арасында мөнәсәбәтләр тагын да кискенләште. Германия генераллары немец гаскәрләрен коткарып калырга тырышалар, ә румын частьларын тар-мар ителүгә һәм юк ителүгә калдыралар. Черкасскида немецлар безне язмыш иркенә ташладылар, ә үзләре качып киттеләр. Бу шәһәрдә һәрбер йорт янында үтерелгән румыннарның гәүдәләре аунап ята иде. Безнең батареябыз үзенең бөтен материаль часте белән, барлык кораллары белән берлектә бөтен составы белән плен бирелде».

* * *

Кеше ашаучы гитлерчылар Ставрополь краеның Советская станицасында колхозчыларны мыскыл иткәннәр. Гитлерчылар гражданнар халкыннан зур бер группаны кулга алып, гестапо төрмәсенә япканнар һәм шунда ерткыч төстә газаплаганнар. Кызыл Армия частьлары омтылышлы удар нәтиҗәсендә, станицаны алдылар, барлык совет гражданнарын азат иттеләр һәм үлемнән коткарып калдылар.

* * *

Красноармейское районында безнең частьлар дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Сугыш нәтиҗәсендә 600 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. Артиллерия һәм бронебойщиклар уты белән немецларның 14 танкысы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Красноград районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта 400 гә якын гитлерчы юк ителде һәм немецларның 3 танкысы яндырылды. 4 транспортер, сугыш припаслары төялгән 30 автомашина, танкка каршы ата торган 5 пушка, 300 дән артык винтовка һәм автоматлар һәм зур бер ашлык склады кулга төшерелде.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Н-че часть сугышчылары немецларның 7 танкысын сафтан чыгардылар һәм бер ротага якын гитлерчыларны юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Икенче бер участокта дошманның 150 автоматчигы безнең сугышчан сафларыбызга үтеп кереп, халык яши торган бер пунктны алган иде. Совет подразделениеләре немец автоматчикларын чолгап алдылар һәм бөтенләй кырып бетерделәр.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм Марьянская район үзәген алдылар. Бу пункт өчен булган сугышта немецларның 200 гә якын солдатлары һәм офицерлары үтерелде. Совет бронебойщиклары немецларның 7 танкысын зарарладылар һәм 3 танкысын яндырдылар. Шуның өстенә дошманның 6 бронемашинасы юк ителде, 7 минометы, 300 автомашинасы, 20 тягачы һәм 10 мең минасы кулга төшерелде.

* * *

Ленинград өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отрядына немецларның зур җәза экспедициясе һөҗүм иткән. Немецлар партизаннарга караганда 5 тапкыр күбрәк булганнар. Шулай булса да совет патриотлары дошманның атакаларын кире кайтарганнар. Карательләр сугыш кырында 170 тән артык үле солдатларын һәм офицерларын калдырып, ашыгыч рәвештә чигенгәннәр. Партизаннар трофейлар алганнар.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Орел өлкәсендәге Сычевка авылының барлык крестьяннарын талап бетергәннәр. Гитлерчы бандитлар авыру колхозчы Иван Щетининны, 70 яшьлек колхозчы Карлованы һәм башка кешеләрне атып үтергәннәр. Немец солдатлары колхозчы Семен Сахуленцевның аягыннан киез итекләрен салдырып алганнар һәм үзен ерткыч төстә кыйнаганнар. Авылдан чигенгән чакта гитлерчылар мәктәпне һәм 17 колхозчының йортын яндырганнар.

* * *

Югославия партизаннары, итальян оккупантларга каршы каты сугышлардан соң Прозор шәһәрен алганнар. Бу шәһәр өчен булган сугышта патриотлар 1.000 нән артык итальян солдатларын һәм офицерларын кырганнар. Партизаннар 6 орудие, 5 танк, 97 пулемет, 500 винтовка, бик күп сугыш припаслары һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшергәннәр.

21 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

21 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть сугышчылары немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр һәм 6 орудие, 15 пулемет, 23 автомашина кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең танкистлар дошманның тылына үтеп керделәр һәм аның бер колоннасына һөҗүм иттеләр. Сугыш кырында 100 дән артык үтерелгән немец солдатлары һәм офицерлары калды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 5 орудие, 2 танк кулга төшерелде һәм 200 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды.

21 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

21 нче февральдә безнең гаскәрләр **Донбасста Боково-Антрацит** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар, шулай ук халык яши торган зур пунктлардан **Верхний** һәм **Нижний Нагольчикны**, **Дьяковоны** һәм башка күп кенә пунктларны алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

14 нче февральдән 20 сенә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында дошманның 276 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 101 самолет югалттык.

* * *

20 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 8 артиллерия һәм 15 миномет батареясының утын бастырдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть кинәт удар ясап, немецларны көчле итеп ныгытылган оборона узелыннан бәреп чыгарды. Сугыш кырында дошманның 300 дән артык үле гәүдәләре калды. Немецларның 2 танкысы юк ителде, 16 пулемет, 180 винтовка һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак булган районда безнең частьлар, һөҗүмне дәвам иттереп, алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта бер батальонга якын немец пехотасы кырып ташланды. 3 танк, 8 орудие, 22 пулемет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Краматорскайдан көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм гаскәрләрнең бер өлеше дошманның контратакаларын кире кайтарды. Бер участокта немецлар бик күп танклар тупладылар һәм хәзер үзләренең югалткан позицияләрен ничек кенә итеп булса да кайтарырга маташалар. Сугышлар бик каты бара. Безнең сугышчылар дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм аның җанлы көчләрен һәм техникасын авыр югалтуларга дучар иттеләр. Бер Эшчеләр поселогы районында Н-че частьның артиллеристлары һәм бронебойщиклары немецларның 7 танкысын зарарладылар һәм мотопехота төялгән 16 автомашинасын юк иттеләр. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошманның 11 танкысын, 2 бронемашинасын юк иттеләр һәм 300 дән артык немец автоматчикларын кырдылар.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че часть бик каты сугышта немецларның 200 гә якын солдат һәм офицерларын кырды, 3 танкысын зарарлады һәм яндырды. Икенче бер участокта безнең танклар һәм моторлаштырылган пехотабыз дошман тылына барып чыктылар һәм халык яши торган бер пунктка урнашкан немецларга кинәт атака ясадылар. Совет сугышчылары бер рота гитлерчыларны кырдылар. Танкка каршы ата торган 4 орудие, 12 автомашина, 2 сугыш припаслары склады, әйберләр склады һәм төрле йөкләр төялгән 30 повозка кулга төшерелде.

* * *

Краснодардан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Ильская тимер юл станциясе районында совет частьлары 67 пулемет, 2.000 винтовка, 12.000 снаряд, 200.000 винтовка патроннары, 6 паровоз, 110 вагон һәм 40 автомашина кулга төшерелде, 200 немец солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

10 нчы февральгә каршы төндә безнең авиациябез Орел өлкәсендәге бер шәһәрдә дошманның казармаларын бомбага тоткан иде. Немец гарнизоны солдатлары арасында паника башланудан файдаланып, Орел өлкәсе партизаннарының бер отряды тимер юл станциясенә үтеп кергән һәм дошманның озатырга әзерләп куелган бер хәрби эшелонын юк иткән. Снарядлар төялгән 3 вагон, танклар төялгән 3 платформа һәм автомашиналар төялгән 2 платформа шартлатылган. Орел өлкәсе партизаннарының икенче бер отряды дошманның бер эшелонын юлдан чыгарган. Һәлакәт нәтиҗәсендә 40 орудие һәм 20 танк зарарланган.

(Ахыры 4 нче биттә).

ЯШӘСЕН АНГЛИЯ — СОВЕТ — АМЕРИКАНЫҢ СУГЫШЧАН СОЮЗЫНЫҢ ҖИҢҮЕ, КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫНЫҢ ЯВЫЗ ДОШМАННАРЫН—НЕМЕЦ-ФАШИСТ КОЛ ИТҮЧЕЛӘРНЕ ҖИҢҮЕ!

(ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ЛОЗУНГЛАРЫННАН)

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

21 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 3 нче биттә)

* * *

16 ай буена фашистлар коллыгында торган Харьков шәһәре халкы авыр җәфалар һәм газаплар кичергән. Гитлерчылар шәһәрне талап бетергәннәр. Меңнәрчә кешеләр ачлыктан, авырулардан һәм немец палачлары кулыннан һәлак булганнар. Немец дивизиясе штабында шартлау булып, шул вакытта бер немец генералы үлгәннән соң, палачлар Харьков халкыннан 2.000 кешене заложниклар итеп кулга алганнар. Бер көн эчендә генә дә гитлерчылар 250 кешене атканнар һәм дистәләрчә кешеләрне балконнарга, фонарь баганаларына һәм агачларга асып куйганнар. Чигенгән чакта гитлерчылар шәһәрдә хәрби әһәмияте булмаган зур биналарны юк иткәннәр. Бандитлар медицина институтын, Харьков университетын, пионерлар сараен, «Спартак» һәм «Интернациональная» гостиницаларын һәм башка җәмәгать биналарын һәм культура йортларын яндырганнар. Немецлар хезмәткә яраклы барлык кешеләрне ирексезләп тылга алып китмәкче булганнар. Полицейскийлар кешеләрне урамнарда һәм өйләргә кереп тотып алганнар һәм вокзалга өстерәп алып киткәннәр. Каршы килүчеләрне шунда ук атып үтергәннәр.

22 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть каты сугышларда 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк итте. 2 танк, 3 орудие, 140 винтовка һәм танкка каршы ата торган 5 мылтык кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең моторлаштырылган пехотабыз гитлерчыларны халык яши торган ике пункттан бәреп чыгарды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта дошман югалткан позицияләрен кире кайтарырга маташып күп кенә контратакалар ясап карады. Н-че частьның сугышчылары гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар. Сугыш кырында дошманның 6 җимерек танкысы, 15 автомашинасы һәм танкка каршы ата торган механикалаштырылган 5 орудиесе калды.

* * *

Красноармейское районында безнең частьлар дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Бер участокта безнең подразделениеләр урнашкан җиргә немец танклары үтеп кергән иде. Безнең артиллеристларның ут һөҗүмнәре белән немецларның 12 танклары җимертелде һәм яндырылды. Дошманның башка танклары качарга маташтылар, ләкин безнең танклар засадасына барып эләктеләр. Немецлар тагын 5 танкларын калдырып, элекке позицияләренә чигенергә мәҗбүр булдылар.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман ашыгыч рәвештә яңа көчләр туплый һәм аларны сугышка кертә. Дошман контратакаларын кире кайтарып, Н-че часть подразделениеләре немецларның 800 гә якын солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта безнең хәрәкәтчел отрядларыбыз халык яши торган берничә пунктны һәм тактик яктан зур әһәмияте булган шоссе юлын алдылар

* * *

Краснодардан көнбатыштарак Н-че берләшмәнең частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. 6 орудие, 17 пулемет, 30 автомашина; атлары һәм йөкләре белән 600 повозка, 2 кием складын һәм 2 азык-төлек складын кулга төшерелде. 150 солдат һәм офицер плен алынды.

* * *

Витебск өлкәсендәге районнарның берсендә хәрәкәт итүче берничә партизаннар отряды, 5 нче февральдән 11 нче февральгә кадәр немецларның сан ягыннан өстен торган көчләренә каршы каты сугышлар алып бардылар. Гитлерчылар партизаннарга каршы эре хәрби частьлар җибәрделәр. Совет патриотлары, кечкенә отрядларга бүленеп хәрәкәт итеп, дошманга флангылардан һәм тылдан кинәт ударлар ясадылар. Сугышларның 6 көне эчендә немецларның 2 батальонга якын пехотасы кырып ташланды.

* * *

Харьков өлкәсенең Малиновка поселогы кешеләре немец-фашист кабахәтләренең ерткычлыклары турында акт төзегәннәр. Актта болай диелә: «Без 16 ай буена немец оккупантлары изүе астында яшәдек. Немецлар поселокның барлык халкын таладылар һәм колхоз хуҗалыгын бөлдерделәр. Бу вакыт эчендә гитлерчы бандитлар Малиновкадан немец коллыгына 800 дән артык кешене көчләп алып киттеләр. Гитлер каторгасыннан качып кайтучылар фашистлар коллыгына төшкән безнең балаларыбызның, ир һәм кыз туганнарыбызның коточкыч хәлләре турында сөйлиләр. Аларны кыйныйлар, ачлык белән һәм түзә алмаслык авыр хезмәт белән җәзалыйлар. Немецлар Малиновкадан чигенү алдыннан төнлә өйләргә кереп йөрделәр һәм эшкә диген булып барлык ирләрне урамга чакырып чыгардылар. Урамга чыгучыларның барысын да гитлерчылар шунда ук атып үтерделәр. Колхозчылардан Илья Чепель, Николай Загребельный, Иван Юдин, Егор Перепелица, Федор Шуга, Григорий Касьянов, Иван Щербина һәм башка бик күп кешеләр шулай атылды. Без бу актны кабахәт немец-бандитларының бу ерткычлыклары турында Кызыл Армия сугышчыларына һәм командирларына һәм бөтен совет халкына сөйләү өчен төзедек. Җирәнгеч һәм кабахәт дошманнан үч алырга барлык совет кешеләрен чакырабыз.

22 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче февральдә безнең гаскәрләр **Украинада Тростянец** шәһәрен, район үзәге **Большая Писаревканы** һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

Кубаньда безнең гаскәрләр халык яши торган зур пунктлардан **Холмскаяны, Ахтырскаяны, Черноерковскаяны** һәм башкаларны алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

21 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар, 6.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар һәм бер сакчы корабльн зарарладылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр. Н-че часть 300 гә якын гитлерчыны кырды һәм бер артиллерия батареясы, 9 миномет һәм күп сугыш припаслары кулга төшерелде. Командиры кече лейтенант Комерный булган подразделениенең бронебойщиклары немецларның 6 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр, алга таба барып, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта совет подразделениеләре 200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын чолгап алдылар һәм кырып бетерделәр. Шуның өстенә гитлерчыларның чолганып алынган гарнизонга ярдәмгә килүче бер ротасы тар-мар ителде. Төрле йөкләр төялгән 30 автомашина, күп автоматлар, винтовкалар һәм сугыш припаслары кулга төшерелде. Икенче бер участокта бер разведка отряды немецларның сугыш припаслары һәм азык төяп бара торган обозын юк итте.

* * *

Красноармейское районында безнең частьлар дошман танкларының һәм мотопехотасының бик каты контратакаларын кире кайтардылар. Бер участокта совет танкистлары немецларның 9 танкысын, 2 бронемашинасын, танкка каршы ата торган 8 орудиесен һәм пехота төялгән 12 автомашинасын юк иттеләр. Н-че берләшмә сугышчылары дошманга каршы сугышларның 3 көне эчендә немецларның 70 кә якын танкысын зарарладылар һәм яндырдылар.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Бер участокта немецлар пехотасы 18 танк ярдәме белән, контратакага күчкән иде. Иптәш Гусев командалыгындагы частьның сугышчылары дошманны элекке позицияләренә алып ташладылар. Бу сугышта дошман бик күп җанлы көчләрен югалтты. Немецларның 7 танкысы сафтан чыгарылды. Икенче бер участокта совет подразделениеләре халык яши торган берничә пунктны алдылар, трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар.

* * *

Сумы өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның бер группа партизаннары бер тимер юл станциясенә бәреп кергәннәр һәм немец сакчыларыннан 38 кешене үтергәннәр. Партизаннар стрелкаларны шартлатканнар һәм дошманның фронтка җибәрү өчен әзерләп куелган бер бронепоездын сафтан чыгарганнар. Чернигов өлкәсе партизаннары февральнең беренче яртысында гитлерчыларның 2 җәза экспедициясен тар-мар иткәннәр. 100 дән артык карательләр үтерелгән. 10 пулемет, 42 винтовка, бер миномет, күп автоматлар һәм бик күп сугыш припаслары кулга төшерелгән.

* * *

Немецларның 302 нче пехота дивизиясенең 572 нче полкыннан плен алынган солдатлар Клеменс Витка һәм Рейнгольд Григорацкийлар болай диләр: «302 нче дивизия декабрь аенда Франциянең Руан провинциясендә ашыгыч рәвештә төзелде. Бу дивизиягә оккупация гаскәрләренең башка берләшмәләреннән тоташ подразделениеләр кертелде. Мәсәлән, 332 нче пехота дивизиясенең һәрбер ротасы 302 нче дивизиягә берәр взвод бирде. 1943 нче елның 1 нче январенда без фронтка чыгып киттек. Хәзер Франциядәге яшь немец солдатларын барысын да Россиягә озаталар. Алар урынына Германиядә армиягә алынган карт резервистлар куела. Без Франциядә чакта кинокартиналар карадык. Экранда немецлар армиясенең бары тик уңышларын һәм җиңүләрен генә күрсәттеләр. Монда, фронтта бөтенесе киресенчә булып чыкты. Фронтка җитәргә дистәләрчә километрлар калганда инде без чигенеп баручы җимерелгән частьларның кызганыч группаларын очраттык. Теткәләнгән, пычранган һәм хәрби тесләрен югалткан бу солдатлар безгә: «Руслар сезне бетерәчәкләр» дигән сүзләр әйтеп җибәрделәр. Шунда ук безнең күпләребезнең рухы төште. Аларның бу сүзләрен беренче сугышлар ук раслады. Безнең полкны бер атна эчендә руслар тар-мар иттеләр».

* * *

Курск өлкәсенең Хмелевский поселогыннан чигенер алдыннан немецлар 30 дан артык йортны яндырганнар. Немец-фашист кабахәтләр халык яшеренгән базаларга гранаталар ыргытканнар. Базларга яшеренгән күп хатын-кызлар һәм балалар үлгән.

Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган тантаналы утырыш

Кичә, Татар дәүләт академия театры бинасында, шәһәрнең партия, совет, профсоюз, комсомол оешмаларының һәм Казан гарнизоны оешмаларының Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган тантаналы утырышы булды.

Президиумда—ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Казан Шәһәр Комитеты бюросы членнары, Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты членнары, хәрби частьларның вәкилләре.

Гаять зур күтәренкелек белән утырышның почетлы президиумы сайлана.

— Сталин! Барысы да урыннарыннан торалар. Бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз, Совет дәүләтенең коралл көчләренең Баш Командующие иптәш Сталин хөрмәтенә көчле ура һәм котлау тавышлары яңгырый.

Җыелышта катнашучылар Молотов, Ворошилов, Калинин, Каганович, Андреев, Жданов, Микоян, Берия, Шверник, Хрущев, Маленков, Щербаков, Вознесенский иптәшләрнең исемнәрен көчле кул чабулар белән каршылыйлар.

Иптәш Щербаков үзенең докладында чирек гасыр эчендә Кызыл Армия тарафыннан үтелгән героик юл турында сөйләде. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендәге совет гаскәрләренең батырлыклары турында, совет җирен гитлерчы шакшылардан азат итеп аларның көнбатышка уңышлы һөҗүм белән алга барулары турында сөйләгәндә, утырышта катнашучылар докладчыны күп тапкырлар көчле алкышлар белән бүлделәр.

Тантаналы утырышка Кызыл Армия сугышчыларының һәм командирларының делегациясе килде. Иптәш Прянишников, үзенең чыгышында данлыклы совет сугышчыларының үз ватаннары алдындагы бурычларын ахырынача үтәргә әзер икәнлекләре турында сөйләде.

Шәһәрнең эшчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре делегациясе исеменнән иптәш Малова чыгып сөйләде.

Аннары Кызыл Армиягә котлау белән пионерлар делегациясе чыкты.

Утырышның ахырында көчле алкышлар астында иптәш Сталинга котлау хаты кабул ителде.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ 1053 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 282